МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное образовательное учреждение
высшего образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Факультет филологии и истории

УТВЕРЖДАЮ
Проректор по образовательной деятельности КФУ
Проф. Д.А. Таюрский
_______________ «___»________20__г.

*подписано электронно-цифровой подписью*

# Программа дисциплины

Родной язык Б1.В.ОД.1.2

Направление подготовки: 44.03.01 - Педагогическое образование
Профиль подготовки: Родной язык и литература
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: заочное
Язык обучения: русский
**Автор(ы):**
Галлямов Ф.Г. , Хайруллина А.С.
**Рецензент(ы):**
Хазиев Ринал Исмагилович

**СОГЛАСОВАНО:**
Заведующий(ая) кафедрой: Даутов Г. Ф.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г
Учебно-методическая комиссия Елабужского института КФУ (Факультет филологии и истории):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No 10160252619


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины
2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы
3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля
4. Структура и содержание дисциплины/ модуля
5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения
6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов
7. Литература
8. Интернет-ресурсы
9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Программу дисциплины разработал(а)(и) профессор, д.н. (профессор) Галлямов Ф.Г. Кафедра татарской филологии Факультет филологии и истории ; доцент, к.н. Хайруллина А.С. Кафедра татарской филологии Факультет филологии и истории , AlSHajrullina@kpfu.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

- овладение прочными теоретическими знаниями в области татарского языкознания с учетом последних достижений тюркологической науки, а также практическими умениями и навыками анализа языковых явлений различных уровней.

- активизация и совершенствование владения нормами татарского литературного языка

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел "Б1.В.ОД.1 Дисциплины (модули)" основной образовательной программы 44.03.01 Педагогическое образование и относится к обязательным дисциплинам. Осваивается на 1, 2, 3, 4 курсах, 1, 3, 4, 5, 6, 7, 8 семестры.

Дисциплина 'Родной язык (синтаксис)' относится к вариативной части профессионального цикла дисциплин основной образовательной программы 44.03.05 Педагогическое образование. Осваивается на 4 курсе (7, 8 семестры).

Для освоения дисциплины 'Родной язык: Синтаксис' студенты используют знания, умения, навыки, сформированные на предыдущей ступени обучения.

Изучение данной дисциплины является необходимой основой для последующего изучения других дисциплин: 'Общее языкознание', 'Историческая грамматика татарского языка' и 'История татарского литературного языка', 'Древние языки', дисциплин по выбору студентов, прохождения педагогической практики, подготовки к итоговой государственной аттестации и т.д.

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ОК 2 (общекультурные компетенции) | способностью анализировать основные этапы и закономерности исторического развития для формирования гражданской позиции |
| Ок 4 | способностью к коммуникации в устной и письменной формах на русском и иностранном языках для решения задач межличностного и межкультурного взаимодействия |
| ОК 5 (общекультурные компетенции) | способностью работать в команде, толерантно воспринимать социальные, культурные и личностные различия |
| ОК 6 (общекультурные компетенции) | способностью к самоорганизации и самообразованию |
| ОПК 1 (профессиональные компетенции) | готовностью сознавать социальную значимость своей будущей профессии, обладать мотивацией к осуществлению профессиональной деятельности |
| ОПК 5 (профессиональные компетенции) | владением основами профессиональной этики и речевой культуры |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ПК 1 (профессиональные компетенции) | готовностью реализовывать образовательные программы по учебным предметам в соответствии с требованиями образовательных стандартов |
| ПК 4 (профессиональные компетенции) | способностью использовать возможности образовательной среды для достижения личностных, метапредметных и предметных результатов обучения и обеспечения качества учебно-воспитательного процесса средствами преподаваемых учебных предметов |
| ПК 6 (профессиональные компетенции) | готовностью к взаимодействию с участниками образовательного процесса |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

- родной язык в его литературной форме и диалектном разнообразии;
- систему и структуру родного языка, роль родного языка в современном обществе;
- особенности фонетических единиц родного языка, законы их функционирования;
- фонетическую и грамматическую систему, словарный состав, стилистические особенности родного языка;
- особенности лексических единиц родного языка, законы их функционирования;
- теоретический материал по синтаксису словосочетания, предложения и текста;

2. должен уметь:

- описывать артикуляцию звуков родного языка;
- давать артикуляционную характеристику гласным и согласным звукам;
- выявлять компоненты лексического значения слова;
- определять основные способы словообразования;
- сопоставлять разные концепции и объяснять причины различной интерпретации однотипного языкового материала;
- анализировать языковые явления;
- анализировать языковые единицы разных уровней;
- разграничивать основные единицы языка и их разновидности;
- употреблять их в соответствии с нормами литературного языка;
- анализировать языковые и лингвостилистические особенности и интерпретировать содержание текста.

3. должен владеть:

- литературными нормами родного языка.
- методикой разбора языкового явления.
- владеть навыками синтаксического анализа словосочетания, простого и сложных предложений разных типов, текста;

навыками:

- синтаксического анализа словосочетания, простого и сложных предложений разных типов, текста;

4. должен демонстрировать способность и готовность:

- демонстрировать владения основными методами, способами и средствами получения, хранения, переработки информации;
- применять результаты освоения дисциплины в профессиональной деятельности.
- применять современных методов и приемов для решения актуальных проблем в области лингвистики;
- использовать основную терминологическую базу языкознания

## 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

Общая трудоемкость дисциплины составляет 25 зачетных(ые) единиц(ы) 900 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины: экзамен в 1 семестре; экзамен в 3 семестре; экзамен в 4 семестре; экзамен в 5 семестре; экзамен в 6 семестре; экзамен в 7 семестре; экзамен в 8 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

**Тематический план дисциплины/модуля**

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 1. | Тема 1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика. | 1 | | 2 | 0 | 0 | Тестирование |
| 2. | Тема 2. Татар теленең авазлар системасы. | 1 | | 0 | 2 | 0 | Реферат |
| 3. | Тема 3. Татар телендә аваз үзгәрешләре. | 1 | | 2 | 2 | 0 | Тестирование |
| 4. | Тема 4. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы. | 1 | | 2 | 0 | 0 | Устный опрос |
| 5. | Тема 5. Татар орфографиясе һәм орфоэпиясе. | 1 | | 0 | 2 | 0 | Устный опрос |
| 6. | Тема 6. Лексикология. Аның тармаклары.Семасиология. | 3 | | 2 | 2 | 0 | Письменная работа |
| 7. | Тема 7. Синонимия, антонимия, омонимия. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. Кулланылыш дәрәҗәсе буенча татар теленең сүзлек составы. | 3 | | 2 | 2 | 0 | Тестирование |
| 8. | Тема 8. Ономастика. | 3 | | 2 | 2 | 0 | Реферат |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практи-ческие занятия | Лабора-торные работы | |
| 9. | Тема 9. Фразеология. | 3 | | 2 | 2 | 0 | Устный опрос |
| 10. | Тема 10. Лексикография. | 3 | | 0 | 2 | 0 | Устный опрос |
| 11. | Тема 11. Сүзъясалышы һәм аның тел белемендә тоткан урыны. | 4 | | 2 | 0 | 0 | Тестирование |
| 12. | Тема 12. Морфемика һәм аның тел белемендәге тоткан урыны. | 4 | | 2 | 2 | 0 | Тестирование |
| 13. | Тема 13. Сүзләрнең сүзъясалыш структурасы. | 4 | | 2 | 2 | 0 | Устный опрос |
| 14. | Тема 14. Татар телендә сүз ясалу ысуллары. | 4 | | 2 | 0 | 0 | Реферат |
| 15. | Тема 15. Төрле сүз төркемнәренең ясалышы. | 4 | | 0 | 2 | 0 | Реферат |
| 16. | Тема 16. Морфология. Татар телендә сүз төркемнәре. Сүзләрне төркемләү мәсъәләсе. | 5 | | 2 | 0 | 0 | Устный опрос |
| 17. | Тема 17. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. | 5 | | 0 | 2 | 0 | Реферат |
| 18. | Тема 18. Сыйфат һәм аның үзенчәлекләре. | 5 | | 2 | 0 | 0 | Реферат |
| 19. | Тема 19. Татар телендә рәвеш һәм аның үзенчәлекләре. | 5 | | 0 | 2 | 0 | Письменная работа |
| 20. | Тема 20. Саннар һәм аларның төркемчәләре. | 5 | | 2 | 2 | 0 | Письменная работа |
| 21. | Тема 21. Алмашлыкларның семантик һәм грамматик төркемчәләре. | 5 | | 2 | 0 | 0 | Тестирование |
| 22. | Тема 22. Исемләшү. Исемнән башка сүз төркемнәренең килеш һәм тартым белән төрләнеше. | 5 | | 0 | 2 | 0 | Тестирование |
| 23. | Тема 23. Татар телендә ярдәмче фигыльләр. Затланышлы фигыльләр. Затланышсыз фигыльләр. | 6 | | 0 | 2 | 0 | Реферат |
| 24. | Тема 24. Аваз ияртемнәре. Модаль сүз төркемнәре. Хәбәрлек сүзләр. | 6 | | 0 | 0 | 0 | Тестирование |
| 25. | Тема 25. Бәйләгеч сүз төркемнәре. | 6 | | 0 | 0 | 0 | Устный опрос |
| 26. | Тема 26. Синтаксиска караган гомуми мәсьәләләр. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше | 7 | | 2 | 2 | 0 | Устный опрос Письменная работа |

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практи-ческие занятия | Лабора-торные работы | |
| 27. | Тема 27. Сүзтезмә. Җөмләнең кисәкләргә традицион бүленеше. | 7 | | 2 | 2 | 0 | Реферат |
| 28. | Тема 28. Җөмләнең иярчен кисәкләре.Аныклагыч һәм җөмләнең модаль кисәкләре.Аерымланган иярчен кисәкләр | 7 | | 2 | 2 | 0 | Устный опрос Письменная работа |
| 29. | Тема 29. Җөмләдә сүз тәртибе. Өстәлмәләр.Бер составлы җөмләләр | 7 | | 2 | 2 | 0 | Письменная работа |
| 30. | Тема 30. Кушма җөмлә синтаксисы. Тезмә кушма җөмлә. Иярченле кушма җөмлә. | 8 | | 2 | 0 | 0 | Тестирование |
| 31. | Тема 31. Иярчен җөмләләрне мәгънә ягыннан төркемләү. Ия һәм хәбәр җөмләләр. Тәмамлык һәм аергыч җөмлә үзенчәлекләре. Иярчен хәл җөмләләр. Максат, шарт, кире җөмләләр. | 8 | | 0 | 2 | 0 | Устный опрос |
| 32. | Тема 32. Аныклагыч җөмлә үзенчәлекләре.Катлаулы кушма җөмлә.Текст синтаксисы.Тезем. Чит сөйләмле текст. Татар пунктуациясенең фәнни нигезләре | 8 | | 0 | 2 | 0 | Устный опрос Письменная работа |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 1 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 3 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 4 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 5 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 6 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 7 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 8 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| | Итого | | | 40 | 44 | 0 | |

### 4.2 Содержание дисциплины

**Тема 1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика. Фонетиканың өйрәнү объекты һәм предметы. Татар теле фонетикасын өйрәнү тарихы. Фонетист галимнәр һәм татар теле фонетикасына өлеш керткән шәхесләр. Сөйләм авазларын өч аспектта өйрәнү.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

**Тема 2. Татар теленең авазлар системасы.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Фонетиканың теоретик әһәмияте дә зур. Һәрбер тел - иң беренче чиратта, авазлар теле. Авазлар телдәге төп берәмлекләрнең - морфемаларның, сүз, сүзтезмә, җөмләләрнең - материаль тышчасын тәшкил итәләр. Алардан тыш тел була алмый. Сүзләрнең мәгънәләре аваз тезмәләрендә реальләшә. Фонетика, тел тарихын, сүзләрнең килеп чыгышын, телләр кардәшлеген өйрәнгәндә, шулай ук зур роль уйный.

**Тема 3. Татар телендә аваз үзгәрешләре.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Сөйләм аппараты. Аваз артикуляциясе. Татар вокализмы. Авазларның характеристикалары. Иҗек. Татар теле консонантизмы. Авазларның характеристикалары. Сөйләм авазлары акустик яктан бер-берсеннән көче һәм югарылыгы белән генә түгел, тембры белән дә аерыла. Авазларның тембр ягыннан бизәлешен тирбәлә торган җисем тудырган өстәмә һава дулкыннары - обертоннар барлыкка китерә. Акустик яктан авазлар шулай ук күләме, ягъни озынлыгы-кыскалыгы буенча да характерлана. Авазның озынлыгы анны әйтү өчен киткән вакыт белән билгеләнә һәм миллисекундлар белән үлчәнә.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Акустик яктан сузык һәм тартык авазлар тон һәм шауның катнашу-катнашмавы белән аерылалар. Сузык авазлар нигездә бары тоннан гына торалар, ә тартыкларны әйткәндә шау да катнаша.

**Тема 4. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Татар телендә комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләре. Ассимиляция. Аккомодация. Диссимиляция. Аларның татар сөйләмендә үзенчәлекләре. Диахроник һәм синхроник вариантлары. Протеза, эпентеза, эпитеза, диэреза, апокопия, редукция.

**Тема 5. Татар орфографиясе һәм орфоэпиясе.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Сөйләмдәге аваз үзгәрешләрен, ни сәбәпле булуларыннан чыгып, икегә бүлеп карыйлар: комбинатор үзгәрешләр, алар авазларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка киләләр; позицион аваз үзгәрешләре - авазларның сүздәге урынына, позициясенә мөнәсәбәтле рәвештә туалар.

**Тема 6. Лексикология. Аның тармаклары.Семасиология.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Татар лексикологиясе фәне. Аның өйрәнү предметы, бурычлары һәм тарихы. Сүзнең төп билгеләре. Сүз һәм предмет. Сүз һәм төшенчә. Сүзнең мәгънәләре. Лексикологиянең тармаклары буларак семасиология, фразеология, лексикография, этимология, диалектология, ономастика һ.б. Сүздә лексик, сүзьясалыш, грамматик (морфологик һәм синтаксик) һәм стилистик мәгънәләр аерылып чыга. Лексикологиядә лексик мәгънәләр өйрәнелә. Сүзнең лексик мәгънәсе конкрет һәм индивидуаль, һәр лексик мәгънәнең үз сүзе бар: урам, таң, карау, кичә, кызыл, өч, теге һ.б

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Семасиология. Аның өйрәнелү объекты. Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның типлары. Лексик мәгънәләрнең чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә төркемләнүе. Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Метафора, синекдоха, метонимия, функция буенча күчеш, табу һәм эвфемизмнар. Семасиология торләре.

**Тема 7. Синонимия, антонимия, омонимия. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. Кулланылыш дәрәҗәсе буенча татар теленең сүзлек составы.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Синонимнар (лексик һәм грамматик синонимнар; идеографик, стилистик, абсолют, контекстуаль синонимнар), синонимик рәт, антонимнар (даими һәм контекстуаль антонимнар; оксюморон, катахреза) һәм омонимнар (татар телендә омонимнар ясалышлары, лексик-семантик һәм грамматик мәгънәләре, әйтелеш һәм ясалыш үзенчәлекләре буенча төрләре), аларның төрләре, барлыкка килү юллары, сөйләмдәге һәм матур әдәбияттагы рольләре.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең лексикасы. Пассив һәм актив лексика. Тарихи сүзләр, архаизмнар һәм неологизмнар. Аларның төрләре. Хәзерге заманда кулланылышы. Искергән сүзләрнең стилистик вазифалары. Тел белеме һәм лексикология буенча хезмәтләрдә, гадәттә, әдәби телнең сүзлек составы килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм кулланылыш активлыгына карап төркемләнә һәм аларның һәркайсы аерым өйрәнелә. Кулланылыш даирәсе ягыннан телнең сүзлек составын иҗтимагый-территориаль яктан диалект лексикасына, социолингвистик яктан - терминологик, һөнәри, жаргон, арго төрләренә бүленеш сакланып килә.

**Тема 8. Ономастика.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Топонимика һәм антропонимика. Лексик-семантик яктан топонимнарның төркемнәре. Кеше исемнәренең килеп чыгышы. Кушаматлар. Псевдонимнар. Татар исемнәренә башка телләрнең йогынтысы.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Ономастика- лексикологиянен ялгызлык исемнэрен ойрэнэ торган тармагы. Узенен берничэ тармагы: топонимика, антропонимика, зоонимика, космономика х.б.

**Тема 9. Фразеология.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Татар фразеологиясе. Татар фразеологиясе өлкәсендә эшләүче галимнәр. Фразеологизмнарның төрләре, бер-берсеннән аерып тора торган билгеләре. Ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләренең аермасы.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Фраезологияне гадэттэ тубэндэге тошенчэлэргэ булэлэр: идиоиалар, фразеологие берэмлеклэр, фразеологик тезмэлэр, х.б.

**Тема 10. Лексикография.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Татар лексикографиясе. Сүзлекләрнең төрләре. Энциклопедик һәм филологик сүзлекләр. Бер телле һәм күп телле сүзлекләр. аңлатмалы, тарихи, тулы, кыскача, әдәби тел, диалектологик, фразеологик, терминологик, орфографик, орфоэпик, язучылар теле, синонимик, антонимик һ.б. Лексикография - суззеклэр тозу теориясен хэм практикасын ойрэнэ.

**Тема 11. Сүзъясалышы һәм аның тел белемендә тоткан урыны.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Сузьясалышы фәне, аның өйрәнү предметы һәм бурычлары: Озак вакытлар сүз ясалышы морфологиянең бер бүлеге буларак өйрәнелеп килде. Хәзерге вакытта исә сүз ясалышының аерым тел белеме тармагы булуы һәм аны мөстәкыйль өйрәнү кирәклеге дәлилләнә. Бу фикерләрне кире какмастан, татар телендә сүз ясалышының морфология белән бик күп уртак яклары булуын истә тотарга кирәк дип саныйбыз. Татар телендә сүз ясалышының күп төрле ысуллары бар, һәм алар һәркайсы тел белеменең аерым тармагы белән бәйләнештә тора.

**Тема 12. Морфемика һәм аның тел белемендәге тоткан урыны.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Морфемалар, аларның төрләре. Сүзнең мәгънәгә ия иң кечкенә берәмлеге буларак морфема. Аның төрләре: тамыр, кушымчалар. Кушымчаларның төрләре: сүз ясагыч һәм грамматик кушымчалар (форма ясагыч һәм сүзбәйләгеч кушымчалар). Үле кушымчалар. Сүз ясагыч кушымчаларның төрләре: исем, сыйфат, рәвеш, фигыль, алмашлык ясаучы кушымчалар.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

*практическое занятие (2 часа(ов)):*

Форма ясагыч кушымчалар: исемдә сан, фигыльдә заман, юнәлеш, дәрәҗә, барлык-юклык кушымчалар. Сүзбәйләгеч кушымчалар: исемнәрдә тартым, килеш, фигыльләрдә зат-сан кушымчалары.

**Тема 13. Сүзләрнең сүзъясалыш структурасы.**

*лекционное занятие (2 часа(ов)):*

Сүзнең грамматик һәм формаль күрсәткечләреннән башка булган өлеше - сүз ясалышы структурасын тәшкил итә. Нигезгә өстәлгән яки кушылган барлык нәрсә морфологик күрсәткечләр булып тора һәм ул морфологиядә өйрәнелә. Морфология һәм сүз ясалышы структуралары арасында тигезлек билгесе куеп булмый.

*практическое занятие (2 часа(ов)):*

Сүзнең грамматик һәм формаль күрсәткечләреннән башка булган өлеше - сүз ясалышы структурасын тәшкил итә. Кунегуләр эшләү.

**Тема 14. Татар телендә сүз ясалу ысуллары.**

*лекционное занятие (2 часа(ов)):*

Телдә сүз ясалу ысуллары бер генә төрле түгел. Татар теленең академик грамматикасында сүз ясалуның сигез төрле ысулын билгелиләр. Әлеге ысулларны икегә аералар: - грамматик юл белән сүз ясалышының морфология, шулай ук синтаксис белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы һәм аларны үзара бәйләнештә өйрәнү зарурлыгы түбәндәгеләр белән аңлатыла.

**Тема 15. Төрле сүз төркемнәренең ясалышы.**

*практическое занятие (2 часа(ов)):*

Фонетик ысул белән суз ясалышы. Бу ысул белән сүзләр ясалышына телчеләрдән беренче булып Г.Алпаров игътибар итә. Фонетик сүзьясалышына шулай ук Ф.С.Фасеев һәм К.С.Сабиров та тукталалар. Татар телендә фонетик ысул белән сүзьясалышының түбәндәге алымнары бар: мматик булмаган ысуллар: 1) аваз яки авазлар төшеп калу;.2) авазның яки авазларның чиратлашуы; 3) нигезнең палатальләшүе (нечкәрүе); 4) басым күчү.

**Тема 16. Морфология. Татар телендә сүз төркемнәре. Сүзләрне төркемләү мәсъәләсе.**

*лекционное занятие (2 часа(ов)):*

Морфология фәне. Аның өйрәнү предметы һәм бурычлары Морфологиянең тел белеменең башка тармаклары белән бәйләнеше. Грамматик категория турында төшенчә, грамматик мәгънә, грамматик форма. Татар телендә сүзләрне төркемләү принциплары: лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик принциплар. Татар телендә сүз төркемнәре.Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Исем- сыйфат мөнәсәбәте, сыйфат-рәвеш мөнәсәбәте.

**Тема 17. Мөстәкыйль сүз төркемнәре.**

*практическое занятие (2 часа(ов)):*

Татар телендэ мостэкыйль суз торкемнэре: исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рэвеш. Исемләшү - үзлегеннән төрләнми торган сүз төркемнәренә хас күренеш. Исемләшү сыйфатлар, рәвешләр, саннар, кайбер алмашлыклар, сыйфат фигыльләр ачыклаган исем җөмлә эчендә кулланылмаса, яки әлеге сүз төркемнәре урыннарын алышса күзәтелә. Хәзерге заман сыйфат фигыль күплек санда кулланылган, җөмләдә ия буып килгән, чөнки ачыкланган исеме җөмләдә төшеп калган. Килеш - исемнәргә хас булган универссаль категория. Ул исемнәрне башка сүз төркемнәренә бәйли, алар арасында төрле грамматик мәгънәләр урнаштыра һәм исемнәрне төрле җөмлә кисәкләре итеп формалаштыра. Сан - предметның бер яки бердән күп булуын белдерә торган грамматик категория. Тартым - татар теленә хас булган үзенчәлекле грамматик категория. Ул предметның кайсы затка караганлыгын

**Тема 18. Сыйфат һәм аның үзенчәлекләре.**

*лекционное занятие (2 часа(ов)):*



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Сыйфатларның семантик төркемчәләре, исемләшүе, дәрәҗә формалары. Лексик-грамматик мәгънәсе буенча татар телендәге сыйфат предметның билгесен белдерә. Билгене белдерү мәгънәсе сыйфатларны башка сүз төркемнәреннән аерып тора. Аңа кеше һәм хайван, кош-кортларга хас булган тышкы һәм эчке билгеләрне белдерә торган сүзләр, урын-араны, күләм һәм форманы, төс һәм тәмне, урынга һәм вакытка мөнәсәбәттән килеп чыккан билгене, үтәүчедән аерылган эш-хәрәкәткә бәйле һ.б. билгеләрне белдергән сүзләр керә. Морфологик яктан сыйфатлар татар телендә төрләнмәүләре белән аерылып тора, ягъни аларга хас булган грамматик категорияләр юк. Предметларның саф билгесен белдерә торган асыл сыйфатларның төрле дәрәҗә формалары була. Синтаксик яктан караганда, сыйфатлар, җөмләдә исемне ачыклап, аергыч булалар.

**Тема 19. Татар телендә рәвеш һәм аның үзенчәлекләре.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Рәвешләр лексик-грамматик мәгънәсе буенча эш-хәлнең яки билгенең билгесен белдерә. Морфологик яктан татар телендәге рәвешләр - төрләнми торган сүз төркеме, аның грамматик категорияләре юк. Тик кайбер рәвешләр чагыштыру яки артыклык дәрәҗәсендә кулланыла. Синтаксик яктан караганда, рәвешләр, сыйфат белән рәвешләрне ачыклап килә һәм җөмләдә төрле хәлләр булып килә. Рәвешләр, җөмлә ахырында килеп, хәбәр дә була. Кайбер рәвешләр исем белән бәйләнешкә керә ала һәм җөмләдә аергыч була.

**Тема 20. Саннар һәм аларның төркемчәләре.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Лексик-грамматик мәгънәсе буенча саннар предметның микъдарын, исәбе буенча билгесен белдерә. Саннар предметның саналу тәртибен, чамалап санауны яки төгәл булмаган якынча исәбен һ.б. мәгънәләрне белдерә. Саннар абстракт мәгънәдә дә кулланыла ала. Бу вакытта аларның саналмышы ягъни алар ачыклап килгән исеме булмый. Мондый саннар математик гамәлләр эшләгәндә кулланыла.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Сан суз торкеме буенча кунегулэр эшлэу.

**Тема 21. Алмашлыкларның семантик һәм грамматик төркемчәләре.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Алмашлык. Алмашлык төркемчәләре. Алмашлыкларны төркемләү, Алмашлыкларның мәгънә буенча төркемчәләре: зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, сорау алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклары, юклык алмашлыклары, тартым алмашлыклары. Ясалышлары буенча алмашлыкларның төрләре. Алмашлыкларга морфологик анализ.

**Тема 22. Исемләшү. Исемнән башка сүз төркемнәренең килеш һәм тартым белән төрләнеше.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Исемләшү - үзлегеннән төрләнми торган сүз төркемнәренә хас күренеш. Исемләшү сыйфатлар, рәвешләр, саннар, кайбер алмашлыклар, сыйфат фигыльләр ачыклаган исем җөмлә эчендә кулланылмаса, яки әлеге сүз төркемнәре урыннарын алышса күзәтелә: Телебездә исемнәрне ачыклап килә торган һәм үзлегеннән төрләнми торган сүз төркемнәре җөмләдә исемнән башка кулланыла ала. Бу исемләшү дип атала.

**Тема 23. Татар телендә ярдәмче фигыльләр. Затланышлы фигыльләр. Затланышсыз фигыльләр.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Татар телендә ярдәмче фигыльләр шактый күп һәм алар бик актив кулланыла. Без аларны берничә төркемгә бүлеп карый алабыз. 1. Фигыльләр ясый торган ярдәмче фигыльләр - кал, ит, кыл, бул һ.б. сүзләр. 2. Фигыль дәрәҗәләренең аналитик формаларын барлыкка китерә торган ярдәмче фигыльләр. Бу фигыльләр мөстәкыйль мәгънәле сүзләр буларак та кулланыла. 3. Мөстәкыйль мәгънәсе булмаган, ярдәмче буларак кына кулланыла торган фигыльләр. Бу фигыльләр сөйләүченең чынбарлыкка төрле мөнәсәбәтен белдерә. Алар теләк, ният, ихтималлык, мөмкинлек, мөмкин түгеллек, тиешлек һ.б. 1. Теләкне белдерә, бер составлы җөмләдә хәбәр булып килә. 2. Теләк мәгънәсен белдереп, бер составлы җөмләдә хәбәр була, составындагы тартым кушымчасы үтәүче затка күрсәтә. 3. Ният итү, карар кылу мәгъәсендә килә, зат-сан кушымчасы ярдәмче фигыльдә була. 4. Мәҗбүрилек, кирәклек, үкенү, карар кылу, үткәнгә караган ният мәгънәләрен белдерә. Аваз ияртемнәре. Модаль сүз төркемнәре. Хәбәрлек сүзләр. Аваз ияртемнәре татар теленең сүзлек составында шактый зур урын алып тора Бу сүзләр эмоциональ-экспрессив лексикага карый. Аваз ияртемнәре соңгы елларда мөстәкыйль сүз төркемнәренә кертеп өйрәнелә башлады. Алар арасында тормыштагы төрле әйберләргә охшатып ясалган түбәндәге сүзләр бар: а) предмет хәрәкәте тавышына; ә) кеше хәрәкәте тавышына; б) хайван һәм кош-корт тавышына; в) техника тавышына; г) табигать күренешләре тавышларына. Морфологик яктан бу сүз төркеме төрләнмәве белән аерылып тора. Синтаксик яктан алар, фигыльләрне ачыклап килеп, төрле җөмлә кисәкләре була. Аваз ияртемнәре ике төрле була: тавыш тасвирлары һәм образ тасвирлары. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Бәйлекләр белән теркәгечләр бәйләгеч сүз төркемнәре дип йөртелә, чөнки алар сүзләрне яки җөмләләрне бәйли. Алар мөстәкыйль сүз төркемнәреннән бик нык аерылып тора. Бәйлек белән теркәгечләрнең атау функциясе юк. Бу сүзләрнең лексик мәгънәсе дә юк. Бәйлек белән теркәгечләргә морфологик категорияләр хас түгел, алар төрләнмиләр. Бу сүзләр үзләре генә җөмлә кисәге дә булмый (теркәгеч сүзләрдән башкалары). Бәйлек белән бәйлек сүзләр җөмлә кисәкләре составында килә.

**Тема 24. Аваз ияртемнәре. Модаль сүз төркемнәре. Хәбәрлек сүзләр.**

**Тема 25. Бәйләгеч сүз төркемнәре.**

**Тема 26. Синтаксиска караган гомуми мәсьәләләр. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Синтаксис һәм логика фәннәре арасында, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт. Сөйләм һәм фикерләүнең төп берәмлекләре буларак җөмлә һәм хөкемләү. Алар арасында мөнәсәбәт. Җөмлә кисәкләре һәм хөкемләү кисәкләре арасында мөнәсәбәт: субъект, предикат, бәйләү (связь), объект, атрибут төшенчәләре һәм ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл, аныклагач төшенчәләре. Субъект белән ия, үтәүче белән предикат, хәбәр белән процесс арасында мөнәсәбәт. Синтаксис һәм аның төп өйрәнү объекты сөйләм төзелеше. Сөйләм, фикер, чынбарлык, сөйләүче, тыңлаучы төшенчәләренә аңлатма. Сөйләмнең төп үзенчәлекләре ? хәбәрлек (сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәте), модальлек (тыңлаучының чынбарлыкка һәм башка синтаксик төшенчәләргә мөнәсәбәте). Сөйләм берәмлекләре: текст, гади җөмлә, кушма җөмлә, сүзтезмә, сүз, җөмлә кисәге. Шуларның ук синтаксик берәмлекләр дип аталуы. Синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр: логик (универсаль), семантик, формаль синтаксислар. Коммуникатив синтаксис. Контрастив синтаксис. Грамматик синтаксис. Грамматик синтаксисның төп бүлекләре: гади җөмлә синтаксисы, кушма җөмлә синтаксисы, текст синтаксисы. Сүзтезмә синтаксисының җөмлә синтаксисы эчендә генә карала алуы. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлеге булган хәбәрлек һәм модальлекнең белдерелүе.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйләнеш буларак ияртүле бәйләнеш. Ияртүле бәйләнеш нәтиҗәсе буларак тезүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешнең җөмлә оештырудагы рольләре буенча төрләре. Җөмлә барлыкка китерүче бәйләнеш буларак хәбәрлекле мөнәсәбәт. Җөмләне җәенкеләндерүче бәйләнеш буларак төгәлләүле (ачыклаулы) һәм аныклаулы мөнәсәбәт. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар. Төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешнең традицион бүленеше: ярашу, башкарылу, янәшәлек. Сүзләр бәйләнешен өйрәнү тәртибе: сүзтезмәләргә аерып һәм җөмләне кисәкләргә бүлеп өйрәнү.

**Тема 27. Сүзтезмә. Җөмләнең кисәкләргә традицион бүленеше.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Төгәлләүле мөнәсәбәткә нигезләнеп төзелгән синтаксик берәмлек буларак сүзтезмә. Сүзтезмәләрне өйрәнү тарихы. Сүзтезмәләрнең сүз белән охшаш яклары һәм аермалары. Сүзтезмәләрнең җөмлә белән мөнәсәбәте. Сүзтезмәләрне төркемләү принциплары. Сүз бәйләнешенең характерыннан чыгып караганда, сүзтезмәләрнең төрләре: ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләр. Аларның бер-берсенә охшаш һәм аермалы яклары. Гади сүзтезмәләр. Катлаулы сүзтезмәләр һәм аларның типик төрләре. Сүзтезмәләрне өйрәнүдән максат. Өйрәнү максатыннан чыгып, сүзтезмәләрне төркемләү. Сүзтезмәләрне ияртүче кисәктән чыгып төркемләү. Исем сүзтезмәләр. Иярүче кисәккә карап, исем сүзтезмәләрнең төп төрләре: исемле исем сүзтезмә, фигыльле исем сүзтезмә, сыйфатлы исем сүзтезмә, санлы исем сүзтезмә һәм аларның төп үзенчәлекләре. Фигыль сүзтезмәләр. Иярүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, фигыль сүзтезмәләрнең күбрәк очрый торган төркемнәре: исемле фигыль сүзтезмә, фигыльле фигыль сүзтезмә, рәвешле һәм сыйфатлы фигыль сүзтезмә, алмашлыклы фигыль сүзтезмә һәм аларныц төп үзенчәлекләре. Сыйфат сүзтезмәләр һәм аларның үзенчәлекләре. Ияртүче кисәккә карап, сүзтезмәләрнең башка төрләре һәм аларның үзенчәлекләре. Җөмләләрне сүзтезмәләргә таркату алымнары.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Җөмлә кисәкләренең логик-грамматик бүленеше. Җөмләне кисәкләргә бүлүнең сүзләр бәйләнешен өйрәнүдә тоткан әһәмияте. Җөмлә кисәкләрен өйрәнүнең торышы. Сүзләр бәйләнешеннән чыгып, җөмләдә беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге кисәкләрне билгеләү мәсьәләсе. Җөмләнең баш, иярчен һәм модаль кисәкләргә бүленеше. Гади сөйләм тәэсире буларак өстәлмәләрнең активлашуы. Баш кисәкләр Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары, сөйләм төзүдә беренче дәрәҗәдәге рольне уйнаулары. Ике баш кисәкнең хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе яки хәбәрлекнең бер генә баш кисәктә бирелүе. Җөмләнең баш кисәге ? ия. Иянең төп билгеләре. Гади ия, тезмә ия. Иянең белдерелүе һәм аның төп мәгънәләре. Җөмләнең икенче баш кисәге ? хәбәр. Хәбәрнең барлык сүз төркемнәре белән дә бирелә алуы. Тарихи үсеше ягыннан хәбәрне исем хәбәр һәм фигыль хәбәрләргә аеру. Гади хәбәр. Тезмә хәбәр. Кушма хәбәр. Исем хәбәрләр. Гади һәм тезмә хәбәрләр, аларның тарихи формалашулары. Кушма исем хәбәрләр, аларның төрләре һәм мәгънәләре. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр, аларның төрләре. Кушма фигыль хәбәрләр. Сөйләүченең процесска мөнәсәбәтен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр. Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр. Процессның сөйләү моментына мөнәсәбәтен белдерүче кушма фигыль хәбәрләр. Эзлекле яки параллель процессларны белдерүче кушма фигыль хәбәрләр. Ия белән хәбәрнең үзара бәйләнеше һәм бу бәйләнешне белдерүче чаралар. Фигыль хәбәрнең ия белән затта ярашуы. Санда ярашуның үзенчәлекләре. Исем хәбәрнең иягә бәйләнеше. Ия белән хәбәр арасында тыныш билгеләре.

**Тема 28. Җөмләнең иярчен кисәкләре.Аныклагыч һәм җөмләнең модаль кисәкләре.Аерымланган иярчен кисәкләр**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы. Иярчен кисәкләрнең төгәлләүле һәм аныклаулы бәйләнешләрне өйрәнүдә әһәмияте. Иярчен кисәкләрне төркемләү принциплары. Төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе буларак аергыч, тәмамлык, хәл, аларның сөйләм оештыруда икенче дәрәҗәдәге рольне уйнаулары. Аергыч һәм аның төп билгеләре. Исем белән бирелгән аергычлар һәм аларның аерылмышка бәйләнү юллары. Сыйфатлар, рәвешләр, саннар, хәбәрлек сүзләр белән бирелгән аергычлар һәм аларның аерылмышка бәйләнү юллары. Фигыльләр белән бирелгән аергычлар һәм аларның аерылмышка бәйләнү юллары. Тәмамлык һәм аның үзенчәлекләре, төрләре. Туры тәмамлык, аның бирелеше һәм ияртүче кисәккә бәйләнү юллары. Кыек тәмамлык һәм аның бирелеше. Кыек тәмамлыкның мәгънәләре һәм ияртүче кисәккә бәйләнү юллары. Кыек тәмамлыклар һәм урын хәлләрен аеру мәсьәләсе.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Аныклагычларның үзенчәлекләре. Аныклагычның урыны һәм аныкланмышка бәйләнү юллары. Аныклагычның барлык җөмлә кисәкләрен дә аныклап килә алуы. Аныклагычның сөйләм төзүдә өченче дәрәҗәдәге роль уйнавы. Фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычлар. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булган аныклагыч һәм аның аныкланмышка бәйләнү юллары. Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсеннән таррак булган аныклагыч һәм аның аныкланмышка бәйләнү юллары. Фигыльләр белән бирелгән аныклагычлар, аларның төп үзенчәлекләре һәм аныкланмышка бәйләнү юллары. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре. Модаль кисәкләрнең төп үзенчәлекләре, аларның төрләре. Җөмлә эчтәлегенә мәгънә һәм форма ягыннан бәйләнгән булулары. Эндәш сүз һәм аның бирелеше, аның янында тыныш билгеләре. Кереш сүз һәм аның бирелеше, мәгънәләре. Кереш сүзләрне белдерүләреннән һәм мәгънәләреннән чыгып төркемләү.

**Тема 29. Җөмләдә сүз тәртибе. Өстәлмәләр.Бер составлы җөмләләр**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Сөйләмдә сүз тәртибенең роле. Төрле стильләрдә сүз тәртибен белдерүче факторлар. Гадәти язма сөйләмдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар. Тойгылы язма сөйләмдә һәм шигъри сөйләмдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар. Гади сөйләмдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар. Сүз тәртибенең функцияләре. Сүз тәртибенең стилистик функциясе.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Сөйләмә телдәге сүз тәртибенең әдәби телгә үтеп керүе нәтиҗәсендә формалашкан күренеш буларак өстәлмәләр. Өстәлмәләрне өйрәнү тарихы. Өстәлмәләр һәм ким җөмләләр. Өстәлмәләр һәм инверсион кисәкләр. Өстәлмәләрнең стилистик функцияләре. Ике составлы җөмлә үзенчәлекләре. Бер составлы җөмлә үзенчәлекләре. Баш кисәкнең кайсы сүз төркеме белән бирелүенә карап бер составлы җөмләләрне фигыль җөмлә, исем (атау) җөмлә һәм сүз җөмләләргә бүлү. Бер составлы фигыль җөмлә төрләре: билгеле үтәүчеле җөмлә, билгесез үтәүчеле җөмлә. Билгеле үтәүчеле җөмләдә баш кисәкнең бирелеше һәм үтәүченең белдерелү юллары. Билгеле үтәүчеле җөмләнең бер төре буларак инфинитив җөмләләр һәм аларның семантик төркемнәре. Үтәүчене белдерүче сүзләр (җөмлә кисәкләре) һәм формалар. Билгесез үтәүчеле җөмләләрдә баш кисәкнең бирелеше. Гомуми үтәүчеле һәм үтәүчесез җөмләләрне аерып чыгару мәсьәләсе. Исем (атау) җөмләләрнең төрләре, аларда баш кисәкнең бирелүе. Баш кисәге сыйфат һәм рәвешләр белән белдерелгән бер составлы җөмләләрне дә атау җөмләләргә кертеп өйрәнү. Атау җөмләләрнең кулланылышы. Таркалмый торган җөмләләр һәм аларның бер төре буларак сүз җөмләләр. Сүз җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.

**Тема 30. Кушма җөмлә синтаксисы. Тезмә кушма җөмлә. Иярченле кушма җөмлә.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Мөстәкыйль булмаган җөмләләр арасындагы бәйләнешне өйрәнү һәм кушма җөмлә. Кушма җөмләләрне өйрәнү тарихы. Кушма җөмләләрне төркемләү принциплары. Кушма җөмләләрне компонентлар саныннан чыгып төркемләү. Кушма җөмләләрне бәйләнеш төреннән, төзелешеннән чыгып төркемләү. Кушма җөмләләрне мәгънәләреннән (функцияләреннән чыгып) төркемләү. Җөмләләр арасында структур һәм мәгънәви бәйләнеш. Җөмләләр арасында грамматик бәйләнеш һәм аның төрләре. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар: тезү интонациясе һәм тезүче теркәгечләр. Ияртүче бәйләнешне белдерүче чаралар: кушымчалар, бәйлек сүзләр, фигыль формасы, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә торып иярү; мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, көттерү һәм аныклау интонациясе. Бәйләүче чараларның һәркайсына хас төп үзенчәлекләр. Тезмә кушма җөмлә үзенчәлекләре. Тезмә кушма җөмләләрне төзелешеннән чыгып төркемләү. Тезмә кушма җөмләләрне оештыруда интонациянең роле. Тезмә кушма җөмләләрне оештыруда катнаша торган теркәгечләр. Тезмә кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре. Иярчен җөмләләрне билгеләү һәм бу турыдагы карашлар. Иярченле кушма җөмләләрне төзелешеннән чыгып төркемләү: синтетик иярченле кушма җөмләләр һәм аналитик иярченле кушма җөмләләр. Аларның төп үзенчәлекләре: бәйләүче чараның иярчен җөмләдәге хәбәр составында тору-тормавы, иярчен җөмләнең чагыштырмача тәмамланган төсмер алу-алмавы, бәйләүче чараның компонентлар чиген билгеләү өчен нигез була алуы һәм нигез була алмавы, компонентларның урынына бәйле үзенчәлекләр, иярчен җөмләдәге баш кисәкләрнең ярашу-ярашмавы, башка телләрдәге төзелешкә охшау-охшамау һ. б. Аналитик һәм синтетик кушма җөмләләрнең үзара синонимлыгы. Кушма җөмләләрне бер төзелештән икенче төзелешкә үзгәртү принциплары: мәгънә мөнәсәбәтен һәм функцияне саклау, шул ук лексик берәмлекләр белән эш итү, кушма җөмләнең гади җөмләгә күчү мөмкинлеге.

**Тема 31. Иярчен җөмләләрне мәгънә ягыннан төркемләү. Ия һәм хәбәр җөмләләр. Тәмамлык һәм аергыч җөмлә үзенчәлекләре. Иярчен хәл җөмләләр. Максат, шарт, кире җөмләләр.**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Ия һәм хәбәр җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары. Тәмамлык җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары. Аергыч җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары. Хәл җөмлә төрләре һәм аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары. Вакыт, урын җөмлә үзенчәлекләре, рәвеш, күләм, сәбәп җөмләләр һәм аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары. Максат, шарт, кире җөмләләр һәм аларның баш җөмләгә бәйләнеш юллары.

**Тема 32. Аныклагыч җөмлә үзенчәлекләре.Катлаулы кушма җөмлә.Текст синтаксисы.Тезем. Чит сөйләмле текст. Татар пунктуациясенең фәнни нигезләре**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Синтаксисның өйрәнү объекты буларак текст. Тоташ сөйләм, текст һәм җөмлә. Аларда хәбәрлек һәм модальлек. Текстны өйрәнү тарихы. Текстның әдәбият белеме, поэтика һәм стилистика фәннәрендә өйрәнелүе. Текст синтаксисының үзенчәлекләре. Тоташ сөйләмнең иң киң берәмлеге буларак текст. Текстны ике төргә бүлү: макротекст (кыскарак аерым әсәрләр, мәкаләләр, хикәяләр, әсәрләрнең аерым бүлек һәм бүлекчәләре, параграфлары, гариза, беркетмә, справка, мәзәк, хикәя, шигырь һ. б.) һәм микротекст (бер теманы яктыртуга багышланган берничә мөстәкыйль җөмлә, абзац, берничә абзац, ягъни синтаксик бөтен). Абзацның микротекст итеп танылу-танылмау мәсьәләсе. Текстның үзенчәлекле бер төре буларак тезем. Тиземнең санау һәм нәтиҗә бүлекләре, аларның урыннары. Теземнең интонацион үзенчәлеге. Санау өлешенең функциясенә карап, теземнең төрләре. Теземдә тыныш билгеләре. Чит сөйләмне традицион өйрәнү, һәм аны, ?чит сөйләмле текст? дип, текст эчендә өйрәнү. Чит сөйләм турында төшенчә. Чит сөйләм төрләре: Туры сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Туры сөйләмнең үзенчәлекләре: диалог һәм аның үзенчәлекләре, цитата һәм аның үзенчәлекләре. Туры сөйләмнең автор сөйләменә бәйләнеше, туры сөйләмнең автор контекстында урыны, туры сөйләм һәм автор сүзләре арасында синтаксик мөнәсәбәт. Кыек сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Кыек сөйләмнең төрләре: аналитик, модаль һәм синтетик кыек сөйләмнәр. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү. Уртак сөйләм, аның өйрәнелү' дәрәҗәсе һәм үзенчәлекләре. Уртак сөйләм һәм текст. Уртак сөйләмнең матур әдәбиятта тоткан урыны Тыныш билгеләрен төркемләү. Тыныш билгеләре һәм интонация, аларның мәгънә белдерүдә рольләре. Ноктаның куелу урыннары. Сорау һәм өндәү (тойгы) билгеләренең куелу урыннары. Күп нокталарның куелу урыннары. Өтернең куелу урыннары. Нокталы өтернең куелу урыннары. Ике ноктаның куелу урыннары. Сызыкның куелу урыннары. Җәяләрнең куелу урыннары. Куштырнакларның куелу урыннары.

### 4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)

| N | Раздел дисциплины | Се-местр | Неде-ля семе стра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудо-емкость (в часах) | Формы контроля самосто-ятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тема 1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика. | 1 | | подготовка к тестированию | 24 | Тести-рова-ние |
| 2. | Тема 2. Татар теленең авазлар системасы. | 1 | | подготовка к реферату | 27 | Реферат |
| 3. | Тема 3. Татар телендә аваз үзгәрешләре. | 1 | | подготовка к тестированию | 24 | Тести-рова-ние |
| 4. | Тема 4. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы. | 1 | | подготовка к устному опросу | 24 | Устный опрос |
| 5. | Тема 5. Татар орфографиясе һәм орфоэпиясе. | 1 | | подготовка к устному опросу | 24 | Устный опрос |
| 6. | Тема 6. Лексикология. Аның тармаклары.Семасиология. | 3 | | подготовка к письменной работе | 36 | Письмен-ная работа |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел дисциплины | Се-местр | Неде-ля семе стра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудо-емкость (в часах) | Формы контроля самосто-ятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Тема 7. Синонимия, антонимия, омонимия. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. Кулланылыш дәрәҗәсе буенча татар теленең сүзлек составы. | 3 | | подготовка к тестированию | 30 | Тести-рова-ние |
| 8. | Тема 8. Ономастика. | 3 | | подготовка к реферату | 30 | Реферат |
| 9. | Тема 9. Фразеология. | 3 | | подготовка к устному опросу | 20 | Устный опрос |
| 10. | Тема 10. Лексикография. | 3 | | подготовка к устному опросу | 12 | Устный опрос |
| 11. | Тема 11. Сүзъясалышы һәм аның тел белемендә тоткан урыны. | 4 | | подготовка к тестированию | 20 | Тести-рова-ние |
| 12. | Тема 12. Морфемика һәм аның тел белемендәге тоткан урыны. | 4 | | подготовка к тестированию | 30 | Тести-рова-ние |
| 13. | Тема 13. Сүзләрнең сүзъясалыш структурасы. | 4 | | подготовка к устному опросу | 20 | Устный опрос |
| 14. | Тема 14. Татар телендә сүз ясалу ысуллары. | 4 | | подготовка к реферату | 20 | Реферат |
| 15. | Тема 15. Төрле сүз төркемнәренең ясалышы. | 4 | | подготовка к реферату | 20 | Реферат |
| 16. | Тема 16. Морфология. Татар телендә сүз төркемнәре. Сүзләрне төркемләү мәсъәләсе. | 5 | | подготовка к устному опросу | 16 | Устный опрос |
| 17. | Тема 17. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. | 5 | | подготовка к реферату | 16 | Реферат |

| N | Раздел дисциплины | Се-местр | Неде-ля семе стра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудо-емкость (в часах) | Формы контроля самосто-ятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 18. | Тема 18. Сыйфат һәм аның үзенчәлекләре. | 5 | | подготовка к реферату | 48 | Реферат |
| 19. | Тема 19. Татар телендә рәвеш һәм аның үзенчәлекләре. | 5 | | подготовка к письменной работе | 16 | Письмен-ная работа |
| 20. | Тема 20. Саннар һәм аларның төркемчәләре. | 5 | | подготовка к письменной работе | 24 | Письмен-ная работа |
| 21. | Тема 21. Алмашлыкларның семантик һәм грамматик төркемчәләре. | 5 | | подготовка к тестированию | 16 | Тести-рова-ние |
| 22. | Тема 22. Исемләшү. Исемнән башка сүз төркемнәренең килеш һәм тартым белән төрләнеше. | 5 | | подготовка к тестированию | 24 | Тести-рова-ние |
| 23. | Тема 23. Татар телендә ярдәмче фигыльләр. Затланышлы фигыльләр. Затланышсыз фигыльләр. | 6 | | подготовка к реферату | 16 | Реферат |
| 24. | Тема 24. Аваз ияртемнәре. Модаль сүз төркемнәре. Хәбәрлек сүзләр. | 6 | | подготовка к тестированию | 20 | Тести-рова-ние |
| 25. | Тема 25. Бәйләгеч сүз төркемнәре. | 6 | | подготовка к устному опросу | 20 | Устный опрос |
| 26. | Тема 26. Синтаксиска караган гомуми мәсьәләләр. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше | 7 | | подготовка к письменной работе | 25 | Письмен-ная работа |
| 27. | Тема 27. Сүзтезмә. Җөмләнең кисәкләргә традицион бүленеше. | 7 | | подготовка к реферату | 25 | Реферат |

| N | Раздел дисциплины | Се-местр | Неде-ля семе стра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудо-емкость (в часах) | Формы контроля самосто-ятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Тема 28. Җөмләнең иярчен кисәкләре.Аныклагыч һәм җөмләнең модаль кисәкләре.Аерымланган иярчен кисәкләр | 7 | | подготовка к письменной работе | 13 | Письмен-ная работа |
| | | | | подготовка к устному опросу | 12 | Устный опрос |
| 29. | Тема 29. Җөмләдә сүз тәртибе. Өстәлмәләр.Бер составлы җөмләләр | 7 | | подготовка к письменной работе | 25 | Письмен-ная работа |
| 30. | Тема 30. Кушма җөмлә синтаксисы. Тезмә кушма җөмлә. Иярченле кушма җөмлә. | 8 | | подготовка к письменной работе | 25 | Письмен-ная работа |
| 31. | Тема 31. Иярчен җөмләләрне мәгънә ягыннан төркемләү. Ия һәм хәбәр җөмләләр. Тәмамлык һәм аергыч җөмлә үзенчәлекләре. Иярчен хәл җөмләләр. Максат, шарт, кире җөмләләр. | 8 | | подготовка к реферату | 15 | Реферат |
| | | | | подготовка к устному опросу | 10 | Устный опрос |
| 32. | Тема 32. Аныклагыч җөмлә үзенчәлекләре.Катлаулы кушма җөмлә.Текст синтаксисы.Тезем. Чит сөйләмле текст. Татар пунктуациясенең фәнни нигезләре | 8 | | подготовка к письменной работе | 16 | Письмен-ная работа |
| | | | | подготовка к устному опросу | 10 | Устный опрос |
| | Итого | | | | 753 | |

## 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

Освоение дисциплины 'Родной язык: Синтаксис' предполагает использование следующего программного обеспечения и информационно-справочных систем:

Операционная система Microsoft Windows Professional 7 Russian.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Пакет офисного программного обеспечения Microsoft Office 2010 Professional Plus Russian.

Браузер Mozilla Firefox.

Браузер Google Chrome.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе 'ZNANIUM.COM', доступ к которой предоставлен студентам. ЭБС 'ZNANIUM.COM' содержит произведения крупнейших российских учёных, руководителей государственных органов, преподавателей ведущих вузов страны, высококвалифицированных специалистов в различных сферах. Фонд библиотеки сформирован с учетом всех изменений образовательных стандартов и включает учебники, учебные пособия, учебно-методические комплексы, монографии, авторефераты, диссертации, энциклопедии, словари и справочники, законодательно-нормативные документы, специальные периодические издания и издания, выпускаемые издательствами вузов. В настоящее время ЭБС ZNANIUM.COM соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего образования (ФГОС ВО) нового поколения.

## 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

### Тема 1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика.

Тестирование , примерные вопросы:

1. Фонетика фәненә караган өлкә ... а) ортопедия, б) орфоэпия, в) орнитология, г) ортодоксия. 2. Мәгънә аеруда катнаша торган тел берәмлеге ... а) җөмлә, б) сүз, в) морфема, г) фонема. 3. Арткы рәт, ягъни калын пары булмаган нечкә сузык: а) [ә], б) [ү], в) [и], г) [ө]. 4. [а] һәм [ә] сузыкларының дифференциаль билгеләре а) 1, б) 2, в) 3, г) 4. 5. ?[з] ? бер фокуслы өрелмәле тартык? дигән формулировкага туры килгән характеристика а) ясалу урыны, б) ясалу ысулы, в) акустик характеристика, г) озынлык буенча. 6. Яу сүзендә: а) 2 тартык, 1 сузык; б) 2 сузык, 1 тартык; в) 2 сузык кына, г) җаваплар дөрес түгел. 7. Таҗлык сүзендә астына сызылган хәреф: а) өрелмәле яңгырау тартыкны, 6) өрелмәле саңгырау тартыкны, в) аффрикат тартыкны, г) сонор тартыкны билдерә. 8. Яулау сүзендә: а) 1 нче иҗек - ачык, 2 нчесе - ябык; б) икесе дә ачык; в) икесе дә ябык; г) 1 нче иҗек - ябык, 2 нчесе - ачык. 9. Кияүләр сүзенең иҗек модельләрен билгеләгез (с ? сузык, т ? тартык): а) ТС-ТСТ-ТСТ; б) ТС-СС-ТСС; в) ТС-СТ-ТСС; г) ТС-ТСТ-ТСС. 10. Смола сүзе татар теленә кергәндә нинди үзгәреш кичергән? а) протеза, б) эпентеза, в) редукция, г) ассимиляция.

### Тема 2. Татар теленең авазлар системасы.

Реферат , примерные вопросы:

1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика. 2. Татар теле фонетикасын фундаменталь аспектта өйрәнү. 3. Хәзерге заманда татар фонетикасын өйрәнүче галимнәр. 4. Хәзерге заманда эксперименталь фонетикада кулланыла торган техник чаралар. 5. Татар теленең авазлар системасы. 6. Сөйләм аппараты. 7. Авазлар артикуляциясе. 8.Татар вокализмын өйрәнүче галимнәр. 9. Татар консонантизмын өйрәнүче галимнәр. 10. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы 11. Татар телендә басымны өйрәнү тарихы. 12. Татар телендә интонацияне өйрәнү тарихы.

### Тема 3. Татар телендә аваз үзгәрешләре.

Тестирование , примерные вопросы:

1. Фонетика фәненә караган өлкә ... а) ортопедия, б) орфоэпия, в) орнитология, г) ортодоксия. 2. Мәгънә аеруда катнаша торган тел берәмлеге ... а) җөмлә, б) сүз, в) морфема, г) фонема. 3. Сузыкларны төркемләү принципларының саны: а) 1, б) 2, в) 3, г) 4. 4. Татар телендә чагыштырмача кыска сузыклар: а) берәү, б) икәү, в) өчәү, г) дүртәү. 5. Арткы рәт, ягъни калын пары булмаган нечкә сузык: а) [ә], б) [ү], в) [и], г) [ө]- 6. -[у] сузыгы - тар сузык? дигән формулировка туры килгән характеристика а) рәт, б) күтәрелеш, в) иренләшү, г) озынлык. 7. Исемлеккә "ялгыш" эләккән бер сузык авазы булган төркем а) [у], [ү], [и], [о], [ө], б) [а], [ы], [у], [о], [ō], в) [и], [ө], [ә,], [е], [ү], г) [а], [у], [ō], [ē], [ы]. 8. [а] һәм [ә] сузыкларының дифференциаль билгеләре а) 1, б) 2, в) 3, г) 4. 9. [у] һәм [и] сузыкларының дифференциаль билгеләре а) 1, б) 2, в) 3, г) 4. 10. - [з] "бер фокуслы өрелмәле тартык" дигән формулировкага туры килгән характеристика а) ясалу урыны, б) ясалу ысулы, в) акустик характеристика, г) озынлык буенча.

**Тема 4. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы.**

Устный опрос , примерные вопросы:

Тема 1. Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак фонетика. 1.Фонетиканың өйрәнү предметын һәм объекты. 2. Фонетика фәненең төп бурычлары. 3. Сөйләмне барлыкка китерүче чаралар. 4. Фонетиканың төп берәмлекләре. 5. Фонетиканың башка фәннәр белән бәйләнеше. 6. Фонетиканың төрләре. 7. Татар теле фонетикасы буенча беренче мәгълүматлар чагылыш тапкан хезмәтләр. 8. Татар теле фонетикасын өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхесләр. Тема 2. Татар теленең авазлар системасы. 1. Фонетиканың төп берәмлекләре. 2. Фонетиканы өйрәнүдә өч аспект. 3. Авазлар ясауда сулыш органнарының функциясе. 4. Сөйләм аппаратындагы резонаторлар. 5. Аваз ясау этаплары һәм аларның атамалары. 6. Фонетиканы мәктәптә укытуда кыенлыклар. 7. Фонема белән аваз арасындагы аерма. 8. Транскрипция.

**Тема 5. Татар орфографиясе һәм орфоэпиясе.**

Устный опрос , примерные вопросы:

Тема 3. Татар телендә аваз үзгәрешләре. 1. Сузык һәм тартык авазлар арасында нинди аерымлыклар. 2. Аваз үзгәрешләренең комбинатор һәм позицион төрләргә бүленеше сәбәпләре. 3. Әйтелештә дә, язылышта да чагылыш таба торган аваз үзгәреше. 4. Синхроник һәм диахроник ассимиляция. Аларның аермалары. Тема 4. Хәзерге татар әдәби теле просодикасы. 1. Просодиканың компонентлары. 2. Сегмент һәм суперсегмент төшенчәләре. 3. Басымның төрләре. 4. Интонациянең төрләре. 5. Басым һәм интонациянең сөйләмдәге роле. 6. Интонациянең тел белеменең башка өлкәләре белән тыгыз бәйләнеше. Тема 5. Татар орфографиясе һәм орфоэпиясе. 1. Татар орфографиясенең бүгенгесе. 2. Татар орфографиясендә рун язуы. 3. Татар орфографиясендә гарәп графикасы. 4. Татар орфографиясендә латин графикасы. 5. Татар орфографиясендә кириллица. 6. Бүгенге көндә орфографик һәм орфографик нормалар. 7. Орфографиядә һәм орфоэпиядә типик хаталар.

**Тема 6. Лексикология. Аның тармаклары.Семасиология.**

Письменная работа , примерные вопросы:



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

1. Телнең сүзләр җыелмасы ничек атала? а) ономастика, б) лексика, в) диалект, г) стиль. 2. Фонетик яктан формалашкан, билгеле бер мәгънәгә ия булган һәм теге яки бу сүз төркеменә караган тел берәмлеге ул -? ... а) иҗек, б) аваз, в) морфема, г) сүз. 3. Лексикологиянең өйрәнү өлкәсе булмаган җавапны билгеләгез. а) профессионализм, б) историзм, в) диалектизм, г) этноним. 4. Лексикологиянең ялгызак исемнәрен өйрәнә торган тармагы ничек атала? а) фразеология, б) этимология, в) ономастика, г) семасиология. 5. Әйберне атау яки исемләү өчен кирәк булган лексик мәгънә ничек атала? а) конкрет, б) абстракт, в) номинатив, г) күчерелмә. 6. Лексикологиянең барлык төр географик атамаларын өйрәнә торган бүлек а) орономика, б) космонимика, в) топонимика, г) антропонимия. 7. Күчерелмә мәгънәле сүзләргә кайсы җавап туры килми? а) синекдоха, б) метафора, в) метонимия, г) градация. 8. Язу карасы - яшел кара. Аерып бирелгән сүз а) метафора, б) метонимия, в) синекдоха, г) вазифа буенча күчеш. 9. Метафорада күчерелмә мәгънә нәрсәгә нигезләнә? а) кешенең күзенә ташланып торган берәр билгесенә, б) охшашлыкка, в) алмаштыруга, г) бер җавап та дөрес түгел. 10. Кыңгырау чәчәге - кыңгырау шалтырады. Аерып бирелгән сүз а) метафора, б) метонимия, в) синекдоха, г) вазифа буенча күчеш. 11. Антракт вакыты. Тәти зал уртасында гөрләшеп, Ак якалар. Пудралар, Сәнгать хакында серләшеп, Әйләнәләр (Һ.Такташ). Зарифуллин шул урында бүленеп калды, чөнки ишектә сары сатин күренде (М.Мәһдиев) Җөмләләрдә очраган күчерелмә мәгънәле сүзләрнең төрен билгеләгез а) метафора, б) метонимия, в) синекдоха, г) бер җавап та дөрес түгел. 12. Күзләрен мәңгегә йомды. Бу лексикологик күренеш ... а) табу, б) эвфемизм, в) метафора, г) метонимия. 13. Игелек һәм изгелек сүзләре а) омонимнар, б) омофоннар, в) парономаслар, г) паронимнар. 14. Атлар (күплек сандагы исем) һәм атлар (билгесез киләчәк замандагы хикәя фигыль). Болар ... а) саф лексик омоним, б) омоформа, в) омофон, г) омограф 15. Объектив чынбарлыкның бер үк төшенчәсен, күренешен белдерүче, ләкин мәгънә төсмерләре, стилистик яктан төрлелеге белән аерылып торучы сүзләр ... а) антонимнар, б) омонимнар, в) синонимнар, г) паронимнар.

**Тема 7. Синонимия, антонимия, омонимия. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. Кулланылыш дәрәҗәсе буенча татар теленең сүзлек составы.**

Тестирование , примерные вопросы:

16. Өй, урам, аш, күз, биш. Бу сүзләр - а) китапча сүзләр, б) тар кулланылыштагы сүзләр, в) жаргон сүзләр, г) гомумкулланылыштагы сүзләр. 17. 1) ау, таш, бер, кул; 2) мәхәббәт, вөҗдан, хыянәт; 3) прогресс, амбулатория. Бу сүзләрнең бүленеше а) килеп чыгышы ягыннан, б) кулланылыш сферасына карап, в) кулланылыш активлыгына карап, г) сүзлек хәзинәсенең экспрессив-стилистик катламнары буенча 18. Сай - тирән. Болар а) оксюморон, 6) катахреза в) саф антоним, г) энантосемия 19. Кайсы фразеологизмның русча эквиваленты дөрес билгеләнмәгән? а) уклау йоткан - аршин проглотил, б) җиң сызганып - спустя рукава, в) кызыл кар яугач - когда на горе рак свистнет, г) исе дә китми - и в ус себе не дует. 20. Антонимнар нигезендә нинди стилистик чара барлыкка килә? а) диэреза, б) антитеза, в) катахреза, г) метатеза. 21. Кайсы фразеологизмның мәгънәсе дөрес билгеләнгән? а) авыз еру - көлү, б) авыз еру - мыскыл итү, в) авыз еру - хәйлә кору, г) авыз еру - авыру. 22. Окказионализм нәрсә ул? а) очраклы сүз, б) искергән сүз, в) яңа сүз, г) бер жавап та дөрес түгел. 23. Кайсы архаизмның синонимы дөрес билгеләнмәгән? а) инсан - кеше, б) ут - үлән, в) хөррият - ирек, г) гамәли - тырыш. 24. Ясак сүзе ул ... а) неологизм, б) диалектизм, в) архаизм, г) тарихи сүз. 25. Кайсы алынманың татарча синонимы дөрес күрсәтелмәгән? а) мемуар - истәлек, б) анализ - нәтиҗә, в) темп - тизлек, г) скульптор - сынчы. 26. Кайсы фразеологизмның антонимы дөрес билгеләнмәгән? а) уртак тел табу - борчак пешмәү, б) агач кул - куян йөрәкле, в) аркылы төшү - юл кую, г) ахирәт дус - җан дошманы. 27. Бер мәгънәгә караган синонимнар группасы ничек атала? а) синонимик йорт, б) синонимик фатир, в) синонимик оя, г) синонимик багана. 28. Матур, чибәр, зифа, нәфис синонимнарының төрен билгеләгез: а) абсолют, б) идеографик, в) стилистик, г) контекстуаль. 29. Каршылыклы төшенчәләрне бергә кушу, сүзнең лексик мәгънәсенә игътибар итмичә кулану ничек атала? а) антоним, б) окказионализм, в) катахреза, г) фразеологизм. 30. Мәктәп, китап, имтихан, мөгаллим сүзләре кайсы телдән кергән? а) фин-угор, б) инглиз, в) төрек, г) гарәп.

**Тема 8. Ономастика.**

Реферат , примерные вопросы:

1. Лексикология. Аның тармаклары. 2.Тел - милли культура көзгесе. 3. Татар милли характерын чагылдырган лексика. 4. Татар гаиләсенең рухи кыйммәтләре, аларның мәкаль-әйтемнәрдә чагылышы. 5. Семасиология. 6. Җанлы табигатьне белдергән сүзләр символикасы. 7. Җансыз табигатьне белдергән сүзләр символикасы. 8. Ономастика 9. Татар халык әкиятләре геройларының исемнәрендә миллилек. 10. Татар халык авыз иҗатында кулланылган ялгызлык исемнәре (аерым төрне сайлап алу нигезендә) 11. Татар исемнәр системасында борынгы төрки традицияләр. 12. Татар гаиләләрендә исем кушу йолалары. 13. Татар фразеологиясе. 14. Фатих Хөснинең "Җәяүле кеше сукмагы" романында фразеологизмнар составы һәм стилистик кулланышы. 15. Фатих Хөсни прозасында фразеологизмнарның лексик-грамматик бөтенлеге. 16. Г.Ибраһимов иҗатында фразеологизмнар. 17. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә фразеологизмнар. 18. Татар гаиләсенең рухи кыйммәтләре, аларның фразеологизмнарда чагылышы.

**Тема 9. Фразеология.**

Устный опрос , примерные вопросы:

Тема 1. Лексикология. Аның тармаклары. 1. Татар лексикологиясе фәненең өйрәнү предметы, бурычлары. 2. Татар лексикологиясен өйрәнү тарихы. 3. Сүз һәм аның төп билгеләре. 4. Сүз һәм предмет. 4. Сүз һәм төшенчә. 5.Сүзнең мәгънәләре. 6. Лексикологиянең тармаклары. Тема 2. Семасиология. 1.Семасиологиянең өйрәнү объекты һәм предметы. 2. Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның типлары. 3. Лексик мәгънәләрнең чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә төркемләнүе. 4. Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. 5.Метафора. 6. Синекдоха. 7. Метонимия. 8. Функция буенча күчеш. 9. Табу һәм эвфемизмнар. Тема 3. Синонимия, антонимия, омонимия. 1. Лексик һәм грамматик синонимнар, синонимик рәт, доминанта. 2. Идеографик синонимнар. 3. Стилистик синонимнар. 4. Абсолют синонимнар. 5. Контекстуаль синонимнар. 6. Даими һәм контекстуаль антонимнар; оксюморон, катахреза 7.Татар телендә омонимнарның ясалышлары, лексик-семантик һәм грамматик мәгънәләре, әйтелеш һәм ясалыш үзенчәлекләре буенча төрләре. 8. Синонимнарның, антонимнарның һәм омонимнарның барлыкка килү юллары, сөйләмдәге һәм матур әдәбияттагы рольләре. Тема 4. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. 1. Татар телендә рус алынмалары. 2. Татар телендә рус теле аша кергән алынмалар. 3. Татар телендә гарәп алынмалары. 4. Татар телендә фин-угор алынмалары. 5. Алынмаларның татар телендә тоткан урыны. Телнең чисталыгына йогынтысы. 6. Пуризм. Тема 5. Кулланылыш дәрәҗәсе буенча татар теленең сүзлек составы. 1. Пассив һәм актив лексика. 2. Тарихи сүзләр. 3. Архаизмнар. 4.Неологизмнар. 5. Искергән һәм яңа сүзләрнең стилистик вазифалары. Тема 6. Ономастика. 1.Топонимика. Аның тармаклары. Лексик-семантик яктан топонимнарның төркемнәре. 2. Антропонимика. 3.Кеше исемнәренең килеп чыгышы. 4.Кушаматлар. 5.Псевдонимнар. 6.Татар исемнәренә башка телләрнең йогынтысы. Тема 7. Фразеология. 1. Татар фразеологиясе өлкәсендә эшләүче галимнәр. 2. Фразеологизмнарның төрләре, бер-берсеннән аерып тора торган билгеләре. 3. Ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләренең аермасы.

**Тема 10. Лексикография.**

Устный опрос , примерные вопросы:

Тема 8. Лексикография. 1.Сүзлекләрнең төрләре. 2.Энциклопедик сүзлекләр. 3. Филологик сүзлекләр. 4. Бер телле һәм күп телле сүзлекләр. 5. Аңлатмалы, тарихи, тулы, кыскача, әдәби тел, диалектологик, фразеологик, терминологик, орфографик, орфоэпик, язучылар теле, синонимик, антонимик һ.б.

**Тема 11. Сүзъясалышы һәм аның тел белемендә тоткан урыны.**

Тестирование , примерные вопросы:



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

1. Морфема нәрсә ул? а) сүзнең мәгънәгә ия булган иң кечкенә берәмлеге; ә) сүзнең лексик мәгънәгә ия булган иң кечкенә берәмлеге; б) сүзнең грамматик мәгънәгә ия иң кечкенә берәмлеге; в) морфема ул - тамыр. 2. Морфемаларга дөрес бүленгән рәтне күрсәтегез: а) кай-та-лар, сү-зем-не; ә) кит-ә-сез, эш-лә-гән-сез; б) китап-лар-ы-быз-ны, эш-ләр-сез; в) китаб-ын, бала-лар-ыбыз. 3. Бер генә мәгънәле кисәктән торган сүзләр тезмәсе: а) элгеч, җиләк; ә) сандугач, сыерчык,карлыган; б) сүзчән, кайтыр, уйламаган; в) бүген, керпе, алмагач. 4. Ясалма сүзләр рәтен күрсәтегез: а) йөрәк, сукмак, тояк; ә) кием, яшьрәк, алтынчы; б) кием, энием, керем; в) тотка, артка, китапка. 5. Бәйләгеч кушымчалары булган рәтне күрсәтегез: а) саргылт, берәү, китә; ә) бәйрәмнәр, аклар, яшьләр; б) китабы, күлләр, өстәлендә; в) кунак, тукмак, сагынып. 6. Тамыр+сүз ясагыч+форма ясагыч+бәйләгеч+бәйләгеч схемасына туры килерлек сүз: а) игенчеләребез; ә) китапчыгымны; б) дәгъвачыларыбыз; в) кибетчеләрен. 7. Бәйләгеч кушымчалар: а) исемдә сан, фигыльдә заман, зат-сан кушымчалары; ә) исемдә килеш, тартым, сүз ахырында килгән күплек сан кушымчалары һәм фигыльдә зат-сан кушымчалары; б) фигыльдә юнәлеш, исемдә килеш, сыйфатларда дәрәҗә кушымчалары; в) сан төркемчәләре кушымчалары, фигыльдә юклык һәм заман кушымчалары. 8. Тамырдаш сүзләр рәтен күрсәтегез: а) карлы, карлыган, карын; ә) күзге, күзән, күзен; б) җәймә, җәенке, җәен; в) башмак, башваткыч, башлы. 9. Морфологик нигез нәрсә ул? а) сүзнең төрләнә торган өлеше; ә) сүзнең форма ясагыч кушымчадан калган өлеше; б) сүзнең бәйләгеч кушымчадан калган өлеше; в) исемдә тартым, сан кушымчалары белән алынган сүз. 10. Грамматик кушымчалар алар: а) исемдә сан, килеш, тартым кушымчалары; ә) фигыльдә зат-сан кушымчалары; б) исемләшкән сыйфатларда килеш кушымчалары; в) затланышсыз фигыль формалары, юнәлеш, дәрәҗә, заман, юклык кушымчалары, сыйфатларда дәрәҗә кушымчалары, сан төркемчәләре кушымчалары, алмашлык төркемчәләре кушымчалары.

**Тема 12. Морфемика һәм аның тел белемендәге тоткан урыны.**

Тестирование , примерные вопросы:

2 нче вариант 1.Сүзформа составында мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәк: а) морф; ә) морфема; б) тамыр; в) кушымча. 2.Кайсы төркемдәге сүзләрнең барысы да морфемаларга дөрес бүленгән? а) ал-дыр-а, ки-ен-ә-м, кош-ны-ң; ә) иг-ен-ләтә, эш-лә-тә,өй-дән; б) бар-гала-ды, эт-тер-де, кеше-ләр-чә; в) кит-мә-гән, күтәр-ел-де, эш-лә-гәнне. 3. Кайсы төркемдәге сүзләр бер сүз ясалыш оясына керәләр? а) кабак, кабырга, кап; ә) бала, балак, бал; б) бүлмә, бүләк, бүленеш; в) кар, карак, карга. 4.Кайсы төркемдә синтетик сүзләр бирелгән? а) өчаяк, көньяк; ә) КДУ, АКШ; б) куркып китү, алып бирү; в) тракторчы, кунак. 5.Нинди сүзләр кушымчалау ысулы белән ясалмый? а) сан; ә) исем; б) рәвеш; в) фигыль. 6.Кайсы сүздә -ен кушымчасы фигыль ясый? а) төшенде; ә) эшенә; б) киенә; в) игенче. 7. Кайсы сүзнең морфологик нигезе дөрес билгеләнгән? а) сынатмадылар; ә) балаларымны; б) ашатыгыз; в) китапханәчеләр. 8. Сүз ясалышы ягыннан кайсы сүз артык? а) кием; ә) утынчы; б) җырласы; в) ташчы. 9. Полифункциональ кушымчалар кергән сүзләр төркемдә? а) тотка, китапка, ботка; ә) каенлык, утынлык, барырлык; б) бүлмә, төймә, үлмә; в) искечә, кисәкчә, үзенчә. 10. Ясалма сүзләр кайсы төркемдә? а) кабырга, карагач; ә) бавырга, карагач; б) тапкыр, кыйгач; в) аркасында, таба. 11. Кайсы төркемдә сүзтезмәләр тезмә сүз түгел? а) йорт куяны, хис итү; ә) җир җиләге, сабыр итү; б) сатылган мал, эчне бушату; в) үги ана яфрагы, тәэсир итү. 12. Кайсы сүз төркеме барлык төр ысуллар белән дә ясала? а) фигыль; ә) исем; б) сыйфат; в) барлык сүз төркемнәре дә. 13. Нинди сүзләр конверсия ысулы белән ясала алмый? а) рәвеш, ярдәмлек; ә) фигыль, сан; б) исем, сыйфат; в) ымлык, кисәкчә. 14. Кайсы төркемдә лексик-семантик ысул белән ясалган сүзләр бирелгән? а) ташчы, ял; ә) ай, ия; б) акыллы, сөйкемле; в) кара, бүлмә. 15. Кыскартылма сүзләрне төркемнәргә аерыгыз. (а) беренче хәрефләренең исемнәрен кушу, б) беренче авазларын кушу, в - беренче иҗекләрен кушу юлы белән; г) катнаш ысул белән ясалган кыскартылма сүзләр) 1. КДУ. 2. КамАЗ. 3. Продмаг. 4. АКШ. 5. Колхоз. 6. SMS. 7. НАТО. 8.ТИҮ.

**Тема 13. Сүзләрнең сүзъясалыш структурасы.**

Устный опрос , примерные вопросы:

1. "Морфема" һәм "Морф" төшенчәләренең аермалары нидән гыйбарәт? 2. "Сүз" һәм "сүз формасы" төшенчәләрен аңлатып бирегез. 3. "Тамыр" һәм "нигез" төшенчәләренең кайсысы киңрәк? 4. "Тамырлашу" төшенчәсе нәрсәне аңлата? 5. Сүз ясагыч кушымчалар нинди сүз төркемнәре ясыйлар? 6. Сүзбәйләгеч кушымчалар нинди сүз төркемнәренә хас? 7. Форма ясагыч кушымчалар кайсы сүз төркемнәрендә аеруча күп очрый? 8. Форма ясагычлар һәм бәйләгечләр нинди сүз төркемнәренә хас түгел? 9. Нуль морфема нинди сүз төркемнәрендә күзәтелә? 10. Нәрсә ул тамыр? 11. Нәрсә ул кушымча?

**Тема 14. Татар телендә сүз ясалу ысуллары.**

Реферат , примерные вопросы:

1. Телдә синоним кушымчалар. 2. Телебездә омоним кушымчалар. 3. Татар телендә полифункциональ кушымчалар. 4. Татар телендә полисинтетик кушымчалар. 5. Татар телендә үле кушымчалар. 6. Бүгенге көндә исем ясагыч продуктив кушымчалар. 7. Сүзьясалышы фәнен үстерүгә өлеш керткән галимнәр. 8. Татар телендә исемнәр ясалышы. 9. Татар телендә сыйфатлар ясалышы. 10. Татар телендә рәвешләр ясалышы.

**Тема 15. Төрле сүз төркемнәренең ясалышы.**

Реферат , примерные вопросы:

11. Татар телендә фигыльләр ясалышы. 12. Тамыр һәм тамырлашкан сүзләр. 13. Татар телендә аналитик сүзләр. 14. Татар телендә синтетик сүзләр. 15. Татар телендә кыскартылма сүзләр. 16. Татар телендә алынма кушымчалар, аларның кулланылышы. 17. Татар телендә ияртүле бәйләнеш төрләре. 18. Парлы сүзләр арасында мәгънәви бәйләнешләр. 19. Нигезләр кушылу ысулы һәм сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү ысуллары, алар арасында охшаш һәм аермалы яклар. 20. Конверсия ысулы белән төрле сүз төркемнәренең ясалышы. (һәр бирелгән сорауга җавапны мисаллар китереп дәлилләгез)

**Тема 16. Морфология. Татар телендә сүз төркемнәре. Сүзләрне төркемләү мәсъәләсе.**

Устный опрос , примерные вопросы:

1. Морфология фәне. Аның өйрәнү предметы һәм бурычлары. 2. Татар телендә сүзләрне төркемләү принциплары. 3.Татар телендә сүз төркемнәре: мөстәкыйль, ярдәмлек, модаль сүзләр. 4. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Сыйфат-рәвеш мөнәсәбәте. 5. Сүз төркемнәре.Аларны өйрәнү дәрәҗәсе. 6. Сүз төркемнәренең өйрәнелү тарихы. Төрле галимнәрнең бу мәсьәләгә карашлары. 7. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. 8. Мөстәкыйль сүз төркемнәренә хас үзенчәлекләр. Д.Г. Тумашеваның "Хәзерге әдәби теле морфологиясе" хезмәтендә сүз төркемнәренең бүленеше. 9. Традицион грамматикада мөстәкыйль сүз төркемнәре. 10. Сыйфат. Сыйфатның лексик семантик төркемчәләре. 11. Сыйфатның лексик-грамматик, лексик-семантик төркемчәләре, сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатларның ясалышы. 12. Алмашлыкның сөйләмдә әһәмияте нәрсәдә? 13. Алмашлыклар арасында алынма сүзләр бармы? Булса, алар кайсы телдән кабул ителгән?. 14. Алмашлык кайсы сүз төркемен алмыштырып килә? 15. Фигыльнең башлангыч формасына мисаллар китерегз. Структур яктан төрләрен атагыз. 16. Татар телендә эшнең үтәлү дәрәҗәсен нинди юллар белән белдереп була. Мисаллар белән аңлатыгыз. 17. Кайсы фигыльнең төркечәсе исемләшә? Мисаллар китерегез.

**Тема 17. Мөстәкыйль сүз төркемнәре.**

Реферат , примерные вопросы:

1. Татар телендә тамыры фигыль булган оядаш сүзләр. 2. Татар телендә парлы сүзләр, аларның рус телендәге эквивалентлары 3. Татар телендә парлы ияртемнәр һәм ымлыклар-дан ясалган кушма сүзләр 4. Сүзтезмәнең, сүзьясагыч кушымча алып, кушма сүзгә күчүе. 5. татар телендә -лы/-ле кушымчалары белән ясалган билге белдерүче сүзләр . 6. Татар телендә -исем + кил- моделе белән ясалган сүзләр.

**Тема 18. Сыйфат һәм аның үзенчәлекләре.**

Реферат , примерные вопросы:

7. Татар телендә хәрәкәт фигыльләренең күпмәгънәлелеге. 8. Татар телендә кушымчалау ысулы белән сүзләр ясалышы. 9. Татар телендә фразеологик фигыльләр. 10. Татар телендә кушма исемнәр ясалышы. 11. Татар телендә кушымчалау ысулы белән сыйфат һәм рәвеш ясалышының үзенчәлекләре. 12. Татар телендә нигезе сыйфат һәм рәвеш булган ясалма фигыльләр.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

**Тема 19. Татар телендә рәвеш һәм аның үзенчәлекләре.**

Письменная работа , примерные вопросы:

1. Сүзнең мәгънәле кисәкләрен өйрәнә торган бүлек: а) сүз ясалышы; б) мофология; в) сүз төзелеше; г) синтаксис. 2. Яфраклар саргайды җөмләсендәге курсив белән аерып бирелгән сүздә морфемалар чигендә нинди күренеш күзәтелә; а) морфонологик күренеш; б) морфологик күренеш; в) синтаксис күренеш; г) монда бернинди күренеш тә күзәтелми. 3. Теләктәшлек сүзе ничә морфемадан (мәгънәле кисәктән) тора? а) өч; б) дүрт; в) биш; г) алты. 4. Грамматиканың сүзләр, җөмләләр бәйләнешен өйрәнә торган бүлеге а) морфемика; б) морфология; в) сүз ясалышы; г) синтаксис. 5. Грамматиканың яңа сүзләр барлыкка килү ысулларын, юлларын, чарала-рын өйрәнә торган бүлеге бүлеге а) морфемика; б) морфология; в) сүз ясалышы; г) синтаксис. 6. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләргә бүленеше кайсы пунктта дөрес бирелгән а) бор-га-ла-т-тыр-ма-ды; б) бор-гала-т-тыр-ма-ды; в) бор-галат-тыр-ма-ды; г) бор-гала-ттыр-ма-ды; 7. Аягында көчкә басып тора. Бу җөмләдә курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 8. Атыңа ия чыгар (Ф.Хөсни). Ия - җөмләнең баш кисәге. Икенче җөмләдә курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 9. Тугры дус. Туры юл. Курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 10. Кайсы формулировка дөрес: Хикәя фигыль а) зат-сан белән төрләнә; б) юнәлеш белән төрләнә; в) барлык-юклык белән төрләнә; г) заман белән төрләнә.

**Тема 20. Саннар һәм аларның төркемчәләре.**

Письменная работа , примерные вопросы:

11. Һәркөнне кичләрен аяк, кулларыңны юып ятарга кирәк. Бу җөмләдә курсив белән аерылган сүз а) берлек сан һәм килештәге исем; б) баш килештәге исем; в) тартым белән төрләнмәгән баш килештәге исем; г) грамматик мәгънәләре берлек сан, 2 зат берлектәге тартым формасына туры килгән исем. 12. Кайсы формулировка дөрес? Хикәя фигыль а) зат-сан белән төрләнә; б) юнәлеш белән төрләнә; в) барлык-юклык белән төрләнә; г) заман белән төрләнә. 13. Кайсы фигыль кайтым юнәлеше формасы белән килеп яңа сүз ясый? а) бизәнү; б) киенү; в) үтенү; г) юыну. 14. Кайсы асыл сыйфатны чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләренә куеп карап булмый? а) яшь; б) карт; в) үле; г) өлкән. 15. Пәрәмәч! Син дә мондамыни?! Син булып син эшли алмадың. Әйтем шул! Курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүзләрне нәрсә берләшиерә? а) мөстәкыйль сүз булулары; б) икенчебер сүз төркеменә күчеп ясалулары; в) тамыр сүз булулары; г) боларны берни дә берләштерми. 16. Бу теманы кайта-кайта өйрәнергә туры килә. Атлап кайта-кайта арып беттек. Курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүзләр а) икесе дә - парлы рәвешләр; б) икесе дә - хәл фигыль; в) беренчесе - кабатланып килгән хәл фигыльнең рәвешкә күчкән очрагы; г) ике форма да эшнең үтәлү дәрәҗасен белдерә. 17. Син күреп белгән теге адәм авылдан киткән. Бу җөмләдәге курсив хәрефләр белән аерып бирелгән фигыльләрнең а) икесендә дә нуль морфема бар; б) беренчесендә юк, икенчесендә бар; в) беренчесендә бар, икенчесендә юк; г) нуль морфема икесендә дә юк. 18. Раслау җөмлә кайсысы? а) Ел саен авылга кайтмый калмый; б) Монда керергә ярамый; в) Ул бүген килмәде; г) Бүген килергә исәбендә дә юк. 19. Кошлар сайравын мин бик яратам. Кошлар сайрауга мин битараф кала алмыйм. Болар ? а) икесе дә синтетик иярченле кушма җөмләләр; б) икесе дә - җәенке җыйнак җөмлаләр; в) беренчесе - гади, икенчесе синтетик иярченле җөмлә; г) беренчесе - кушма, икенчесе гади җөмлә. 20. Син килүгә мин шатмын. Син килүгә, бу мәсьәләне хәл итәрбез. Син килгәнгә, ул аптырап калды. Бу җөмләләрнең мәгънә төрләре буенча урнашу тәртибе түбәндәгечә: а) вакыт җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә; б) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә; в) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, максат җөмлә; г) тәмамлык җөмлә, күләм җөмлә, сәбәп җөмлә.

**Тема 21. Алмашлыкларның семантик һәм грамматик төркемчәләре.**

Тестирование , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Морфология курсыннан тест биремнәре 1 нче вариант 1.Сүзләрне нәрсәгә таянып төркемлиләр? а) гомумиләштерелгән лексик-грамматик мәгънә; ә) грамматик категорияләр комплексы; б) сүзләрнең синтаксик вазифасы; в) алдагыларның өчесе дә. 2. Грамматик категория а) грамматик формалар системасы; ә) грамматик мәгънәләр җыелмасы, б) грамматик мәгънә һәм грамматик форма бердәмлеге, в) җаваплар дөрес түгел. 3.Су, каймак, ком, нәфрәт, ихтирам, тимер, агач, тәрәзә мисаллары арасында а) предметны белдерә торган ике исем; ә) җыелмалылыкны белдерә торган 3 исем; б) вакыйга-күренешне белдерә торган 2 исем; в) әйберне белдерә торган 4 исем бар. 4.Исем ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? а) -сыл, -сел, -малы,-мәле; ә) -ла,-лә,-ы,-е; б) -ганак,-гәнәк, -ымта, -емтә; в) -а,-ә, -ла,-лә. 5."Идел белән Җаектан, Сарай белән Болгардан, Каргалы, Элек буеннан, Татарның тулы йортыннан Сина килдем, атаем" - өзегендәге исемнәр а) урын хәлләре; ә) аергычлар; б) тәмамлык һәм эндәш сүзләр; в) тәмамлыклар булып килгән. 6. Килеш функциясендә килгән сүз формасы кайсы төркемнәрдә? а) чираттагы утырыш, ә) бүтәнчә уйлау; б) йортыбыздагы маллар; г) эшчән кеше. 7.Җиргә эре бодай бөртекләре чәчелде (Г.Бәширов) җөмләсендәге сыйфат а) предметның формасын; ә) күләмен; б) характер билгесен; в) урынны белдерә. 8.Көлсу, моңсу, алсу, уйсу мисалларының кайсысын кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат дип санап була? а) беренчесен; ә) икечесен; б) өченчесен; в) дүртенчесен. 9.Елмайганда тип-тигез тешләре күренеп китә. Аның тешләре тип-тигез җөмләләрендә курсив белән аерып бирелгән сүзләр а) бер үк җөмлә кисәкләре; ә) беренчесе - хәл, икечесе - хәбәр; б) беренчесе - аергыч, икенчесе - хәбәр; в) беренчесе - тәмамлык, икенчесе - хәбәр. 10.Идрисов фронтка бары тик 1942 елда гына әләгүен әйтеп бирде.Бу җөмләдә сан а) бүлем саны; ә) тәртип саны; б) җыю саны; в) микъдар саны. 11.Кил- һәм бул- фигыльләренең кайсы юнәлештә лексик мәгънәләре үзгәрә. а) йөкләтү; ә) уртаклык; б) кайтым; в) төшем. 12.Кайсы җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыльнең парадигматик мәгънәсе бирелгән? а) Сания пөхтә киенә; ә) Кара әле, әллә нинди бер кош очып бара; б) Иртәгә апаларга барам; в) Ирек мактанырга ярата. 13.Кайтым юнәлешендәге фигыль кайсы төркемдә? а) Кичә укучылар концертка хәзерләнде; ә) Проект ике көндә хәзерләнде; б) Икенче срокка сайланды; в) Йорт бик тиз салынды. 14. Фигыль төркемчәсенең күрсәткече нуль форма булганы кайсысы? а) теләк фигыль; ә) инфинитив; б) исем фигыль; в) боерык фигыль. 15. Ярдәмче фигыль кайсысында? ә) дәвам итә; ә) гөж килү; б) кабул итү; в) укып бетерү.

**Тема 22. Исемләшү. Исемнән башка сүз төркемнәренең килеш һәм тартым белән төрләнеше.**

Тестирование , примерные вопросы:

